СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

28 июнь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 70 (8082) | Бәясе билгеләнгәнчә

## АЯЗ КӨННӘР ГЕЛ БУЛМАС

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

Соңгы бер көндә күпьеллык үләннәр 500 гектар чамасы мәйданнан чабылса да, бу эшнең темпын нык арттыру сорала әле. Дөрес, чабылган кадәресен җыеп печән иттереп урнаштыру соңгы бер - ике көндә ярыйсы ук кызулана төште. Шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгында, Синдряков исемендәге, «Заветы Ильича», «Әлмәт», «Чирмешән», «Якты Күл», «Рассвет», Мичурин исемендәге хуҗалыкларда коры печән запасы өч көндә 90 - 140ар тоннага артты. Аларның соңгысында әлегә печән һаман да иң күбе - 300 тонна. Хәзер инде коры печән һәр хуҗалыкта азмы - күпме булуы куанычлы хәл, әмма гомумән алганда көтеп алынган аяз көннәрнең кадерен белеп бетерү җитми әле.

Витаминлы үлән оны ясау агрегатларының җитештерүчәнлеге арта төшү дә игътибарга лаек. Соңгы өч көндә бу төр кыйммәтле азык запасы Синдряков исемендәге, Мичурин исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, «Игенче», «Кондырча» хуҗалыкларында сизелерлек артты.

Шикәр чөгендере басуларында да эш җитәрлек әле. Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта, МСОның ярдәмче хуҗалыгында чөгендерне беренче кат сирәкләү белән хәл аеруча катлаулы булган бер вакытта «Чирмешән», Мичурин исемендәге, «Рассвет», «Заветы Ильича», «Таң», «Якты Күл» һәм тагын берничә хуҗалыкта аны икенче кат эшкәртү дә бара инде.

## 28 июнь - Яшьләр көне

*Кайчандыр гөрләп торган оешмалары, удар төзелешләре, комсомол- яшьләр бригадалары булган гүзәл һәм дәртле буын бүген нигездә үз-үзенә тапшырылган. Бүгенге яшьләр тормышында күп нәрсә ирекле, күп нәрсә өлкән буынга аңлашылмый.Әмма яшьлекнең төп сыйфатлары-гүзәллек, омтылыш, хыялыйлык беркайчан да җуелмастыр, мөгаен.Һәм, әлбәттә, кайнар йөрәкләре, зирәк акыллары, уңган кулларына лаеклы урын таба алган яшьләребез дә һәркайчан бар. Аларжәмгыятьнең саулыгы, өмете, киләчәге.*

*Бәйрәм белән сезне, кадерле яшьләребез!*



Наталья Борисовна Исаева «Заветы Ильича» күмәк хуҗалыгында алдынгы сыер савучы, тикмәгә генә ул күптән түгел булып үткән район сыер савучылары конкурсында катнашмады. Бүгенге көндә ул һәр сыердан 15 әр килограмм сөт савып ала. Биредә аның хезмәт стажы дистә елны тәшкил итә инде. Мәктәпне тәмамлап үзенең һөнәрен фермадан тапты, озак та үтми гаилә дә корып җибәрде. Тормыш иптәше, хуҗалыкнын автомеханигы Михаил Леонидович белән ике бала тәрбияләп үстерәләр, һәм авылда һәр гаиләдәгечә олы хуҗалык тоталар. Болар Исаевларның күмәк хуҗалыктагы эшләрен җиренә җиткереп башкарырга һич тә комачауламый.

**Рәсемдә: Н.Исаева.**

## Хәбәрләр • Хәбәрләр • Хәбәрләр

### Пенсия түләү - беренче планда

Үзвакытында бирелгән пенсия - өлкән яшьтәгеләр өчен мөһим яшәү чыганагы. Соңгы вакытта район пенсионерлары шөкерана кылып, пенсия түләүләренә тәртип салу өчен районыбыз җитәкчелегенә, аерым алганда район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинга рәхмәт укып яшиләр. Шулай булмыйни,әле күптән түгел генә социаль тәэминат министрлыгында үткән коллегия утырышында пенсия белән тәэмин итү органнарының эшчәнлеген камилләштерү буенча чаралар каралганда да тулаем республика буенча пенсия түләүдәге бурычларның 51 миллиардлап булуы, байтак районнарда әле аны май ае өчен түләү турында сүз барганда, безнең Октябрь районында июнь өчен дә исәп- хисап ясалу ассызыкланды.Хакимиятнең социаль яклау идарәсе начальнигы Л.Н.Дилмөхәммәтованың коллегиядә тәҗрибә уртаклашу ниятеннән ясаган чыгышы да һичкемне битараф калдырмаган.

### Мәдәният хезмәткәрләре укый

26 июньдә район хакимиятенең мәдәният бүлеге клуб хезмәткәрләренең семинар-киңәшмәсен үткәрде.Сүз, нигездә, мәдәният хезмәткәрләрен аттестацияләү турында барды. Ул июльнең 1 декадасына планлаштырыла.Киңәшмәдә шулай ук булачак Уяв чуваш фольклор бәйрәме турында да җитди сүз булды.Катнашучылар алдында район культура йортының баш методисты В.Голубева, мәдәният бүлегенең әйдәп баручы белгече О.Осипова,чуваш җыры халык ансамбле җитәкчесе С.Ефремова чыгыш ясадылар.Семинар эшенә мәдәният бүлеге мөдире Р.Яруллин җитәкчелек итте.

### Сез нәрсә укыйсыз?

Районда 1997 елның II яртысына 2891 данә республика газеталары һәм журналлары алдырачаклар.Моңа 223 миллион сум акча сарыф ителгән.Иң популяр басмалар- «Татарстан яшьләре», «Юлдаш», радио һәм телевидение программасы, «Сам хозяин» һ.б. «Республика Татарстан» газетасын 1126, «Вечерняя Казань»ны - 242 гаилә (бәясе 54 мең!) укыячак.

Үзәк басмалардан район газетасына кадәр бар подписка кампаниясе октябрьлеләргә 942 миллион сумга төште.

## БАРЫСЫ ДА МӨҺИМ

### (Район хакимиятендә киңәшмә)

Район хакимиятендә агропромышленность комплексына кергән һәм аңа мөнәсәбәтле булган барлык хуҗалыклар, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре, җирле үзидарә Советлары рәисләре, авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең баш белгечләре катнашында узган соңгы киңәшмә бу тармакта бүген иң көнүзәк булган бурычларны ничек уңышлы хәл кылу мәсьәләләренә багышланды.

Аны ачып, хакимият башлыгы Ф.С.СИБАГАТУЛЛИН сабан туйларының зур оешканлык белән һәм югары идея - сәяси дәрәҗәдә узуын, моның шулай икәнлеге дәрәҗәле кунаклар тарафыннан да билгеләп үтелүен әйтеп, хезмәт бәйрәмен әзерләү һәм үткәрүдә актив катнашкан һәркемгә рәхмәт белдерде, шул ук вакытта республикабызның башка районнарында узган сабан туйларындагы ат чабышларының шактыенда безнең юртаклар һәм чаптарларның баш килүен, шул исәптән Казан сабантуенда да безнең атлар иң йөгереге булып, «Ледок» кушаматлы юртагыбызның Президент күнеленә иң хуш килгән ат булуын зур канәгатьлек белән билгеләп үтте.

Сабан туйларына язгы кыр эшләрен зур оешканлык һәм сыйфат белән үткәреп килгән булсак, бәйрәм артыннан ук авыл кешесенең яңа мәшәкатьләре дә өстәлде, көндәлек башка эшләре дә даими игътибар сорый. Соңгыларыннан иң мөһиме - терлекчелек, беренче чиратта сөт терлекчелегендәге көнүзәк бурычлар турында киңәшмәдә авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Р.М.Гыйбадуллин чыгыш ясады. Ул сөт җитештерү һәм хәзерләүдә яуланган югары үрләрнең кайбер хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләренең тынычланыбрак калуына китерүенә күрсәтеп, бу тармакта күрсәткечләрне тагын да яхшырту өчен әле шактый ук резервлар булуын ассызыклады. Эш иң беренче чиратта сөтчелектә җәйләү чоры технологиясе таләпләрен тайпылышсыз үтәү, аерым алганда, малларны тәүлек буена көтүгә, өстәмә яшел азык бирүне кимет- мәүгә һәм хәзер инде бу максатларга люцернадан тыш яшел борчакны да куллана башлауга, шуның белән бәйле рәвештә малларны саламнан да өзмәү, рационда концентрат азыкларны да киметмәү, шул ук вакытта көн режимын һәм саву технологиясен төгәл үтәү мәсьәләләренә кайтып кала. Болар белән бергә, продукциянең сыйфаты да күз уңында булырга тиеш.Идарә башлыгы бер үк вакытта савым көтүенең киләчәге турында да даими кайгырту, аерым алганда юнәлешле үстерүдәге таналарга игътибарны арттыру зарурлыгын да ассызыклап үтте. Дуңгызчылык тармагындагы бурычларга кагылып, ул буаз аналарны һәм яшь үрчемне карау һәм ашату технологиясенең тайпылышсыз үтәлергә тиешле мөһим таләпләренә тукталып үтте.

Аның фикерен дәвам иттереп, Ф.С.Сибагатуллин дуңгызчылыкта ныклы тәртип булдыру, бу тармакта эшләүчеләрнең үз хезмәтләренең нәтиҗәлелеге белән кызыксынуын күтәрү максатыннан аларга «Рассвет» хуҗалыгындагыча натуралата түләү практикасын киң кулланылышка кертү мөһимлеген ассызыклады, «Агрохимсервис»ның «Сөлчә» ярдәмче хуҗалыгында да моның уңай нәтиҗә биргәнлеген билгеләп үтте.

( Ахыры 2 нче биттә).

## ● Рәсми хроника

### РӘИСЛӘР АЛЫШЫНА ТОРА...

23 июнь көнне «Игенче» КХАсы членнарының гомуми җыелышы булды.Анда шәхси гаризасы нигезендә хуҗалык рәисе Р.К.Бикиниев вазифаларыннан азат ителде. «Игенче» КХАсы рәисе итеп моңарчы «Надежда» дәүләт предприятиесе директоры булып эшләгән **Равил Сәмигуллович Хәмидуллин** сайланды.

***

Шул ук көнне «Комбайн» КХАсы әгъзалары да гомуми җыелыш уздырдылар. Анда төп мәсьәлә итеп хуҗалык җитәкчесен алыштыру каралды.Рәис М.М.Фәссаховның эштән азат итү турындагы гаризасы канәгатьләндерелде. «Комбайн» КХАсы рәисе итеп **Әхмәт Вәлиәхмәтович Мөлеков** сайланды.

***

26 июнь көнне Кузнецов исемендәге КХА да гомуми җыелыш үтте.Анда хуҗалык рәисе Е.В.Абрамов шәхси гаризасы нигезендә эштән азат ителде. Кузнецов исемендәге КХА рәисе итеп моңарчы халык депутатларының район советы рәисе урынбасары булып эшләгән **Евгений Кузьмич Савинов** сайланды.

# БАРЫСЫ ДА МӨҺИМ

## (Район хакимиятендә киңәшмә)

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Хакимят башлыгы шәхси хуҗалыклардан артып калган сөтне сатып алу эшенә игътибары һич тә йомшартырга ярамавын, җирле үзидарә Советлары рәисләре бу мәсьәләне бүген төп бурычларыннан берсе санарга тиешлекләрен әйтеп үтте. Соңгылары шул ук вакытта торак пунктларны төзекләндерү, санитар чистарту, урамнарны һәм юлларны да үрнәк тәртиптә тоту буенча җитди эш оештырырга чакырылганнар. Сүз уңаеннан, шушы максаттан җыеп алынган чүп үләннәрне витаминлы үлән оны ясауга тоту мәслихәт. Шуны искәртеп, Фатих Сәүбәнович районда терлек азыгы хәзерләү кебек көнүзәк мөһим эшне оешканлык белән башкару буенча алда торган бурычларга җентекләп тукталып узды. Бу җәһәттән бүген күпьеллык үләннәрне беренче кат чабып чыгуны озакка сузмау, моның өчен хәзер көннәр аяз торган зур мөмкинлекне ничек тә отышлы файдаланып калу турында кайгырту, хәзерләнә торган печән һәм сенажның сыйфатын көндәлек контрольдә тоту мөһим, соңгысын яшел массаның дымлылыгы 35 проценттан артык булмаган чакта урнаштырып калу шарт. Башка төр терлек азыклары, шул исәптән яфрак азык һәм дару үләннәре җыйнау эшен дә дәвам итәргә кирәк.

Ф.С.Сибагатуллин киңәшмәдә чәчүлекләрне карау, бу җәһәттән районда мулдан булган гербицидлар башка төр химик чараларны киң куллану, терлек азыгының аксым өлешен ныгыту максатыннан люцернаны җәйге чәчү, бер үк вакытта көзге чәчү турында кайгырта башлау һәм тагын да мөһимрәге - урып -җыюга ныклап әзерләнү мәсьәләләренә җитди карарга кирәклеген ассызыклады.

Киңәшмәдә районның социаль - икътисадый үсешенә кагылышлы башка күп кенә мөһим мәсьәләләр хакында да сүз булды.

## Татарстан Президентының керемнәре һәм милке турында

**Шушы көннәрдә Татарстан Президентының керемнәре һәм милке турында мәгълүматлар бастырып чыгаруны үтенеп, бер төркем укучыларыбыз редакциягә мөрәҗәгать итте. Без үтенечне М.Ш.Шәймиевкә җиткердек һәм Президентның матбугат үзәгеннән түбәндәге мәгълүматны алдык.**

М.Ш.Шәймиевнең хатыны С.Ш.Шәймиева белән уртак күчемсез милкенең декларацияләнгән суммар җыелма кыйммәте 1997 елның 1 гыйнварына 820,6 миллион сум тәшкил итте. Шул исәптән гомуми мәйданы 104 квадрат метрлы, торак мәйданы 64,5 кв. метрлы хосусыйлаштырылган квартирасы бар-611,4 миллион сум. Төзелеп бетмәгән дача бар-аны төзүгә 200 миллион сум акча тотылган, гараж 9 миллион сум тора.

Саклык кассасында М.Ш.Шәймиев кертемнәренең калдыгы 80,7 миллион сум тәшкил итә. Аның дәүләт милкен хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә алынган 54 мең сумлык кыйммәтле кәгазьләре бар.

Чит илдә күчемсез милек объектлары һәм шәхси транспорт чаралары юк.

1996 елда М.Ш.Шәймиевнең декларацияләнгән кереме 90,4 миллион сум тәшкил итә. Еллык кереме төп эш урынындагы җыелма эш хакы һәм премияләрдән, Россия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасына түләүләрдән, мәкаләләр бастырып чыгару һәм чыгыш ясаулардан кергән гонорарлардан, шулай ук Татарстан Республикасы Саклык кассасындагы кертемнәрнең процентларыннан тора.

М.Ш.Шәймиев һәм аның хатыны С.Ш.Шәймиеваның кертемнәре һәм милке турындагы декларацияне алар яшәү урынындагы Салым дәүләт инспекциясенә тапшырдылар.

**(Мәгълүматлар «Республика Татарстан» газетасыннан алынды.)**

## ИГЪТИБАРЛЫ, ТЫРЫШ УЛ



Таныш булыгыз: рәсемдә Людмила Быстрякова. Ул менә инде 15 еллап өрөзлексез дәүләт орлык инспекциясендә эшли. Ул - техник лаборант. Төп вазифасы - инспекциягә китерелгән барлык культураларга анализ үткәрү. Людмила Павловна үз хезмәтен һәрчак төгәл башкара, гел сыйфатлы эшли. Монардан тыш, ул коллективта язу машинасында басу остасы буларак та хөрмәт казанды.

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## АВЫЛ: Кичә. Бүген. Иртәгә

# ЭШЛӘРЕНӘ КҮРӘ АШЛАРЫ

«Сөлчә»нең маллардан мул продукция җитештергән, күп санлы савым осталары белән дан тоткан вакытлары аз түгел иде. Әмма соңгы берничә елда сөт терлекчелегендә эшләр үзагымга куелгач, барлык күрсәткечләр дә сизелерлек түбән тәгәрәде. Яртышар ел хезмәт хакы ала алмаган терлекчеләрнең дә эшкә күңелләре үсмәде: айлар буе бушка эшләп йөргәнче, фермадан сөт, терлек азыгы «чәлдереп» кайтып көн күрүне кулай күрделәр алар.

Бүген исә хуҗалыкта бөтенләй башка атмосфера. Районда үткәрелә торган киңкырлы реформалар Мамык авылына да килеп җитте, ярдәмче хуҗалык буларак «Сөлчә» «Агрохимсервис» АҖ нә тапшырылгач (1996 нчы ел азагыннан) биредә зур үзгәрешләр барлыкка килде. Кышка карап тормыйча, фермаларда ремонт эшләре башланды. Иң элек каплату яшендәге бозаулар бәйсез асрау режимына күчерелде. Тагын 200 баш савым сыерын шулай асрау өчен бина хәзерләнде. Җәйге лагерьның кардасы тулысынча төзәтелде, сууткәргеч ясалды. Башка абзарларның торышы да анализланып, аларны төзәтү-реконструкцияләү буенча конкрет бурычлар билгеләнде.

Малларны ашату, фермаларны ышанычлы кадрлар белән комплектлау да беренче чиратта хәл ителергә тиешле бурычлар рәтенә кертелде. Һәм, иң мөһиме... эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү мәсьәләсе хәл ителде. Кыштан бирле мамыклылар һәр айның уннарында акча алалар.

Билгеле инде, алда телгә алынган факторларның нәтиҗәсе булмый калмый. Иң элек, савым арта башлый. Маллар җәйге лагерьда яши башлап, җәйге рационга күчерелгәч ул һәр сыердан уртача 17,9 килограммга җитте хәтта. Бу узган елның шул чорындагыдан 5,9 килограммга күбрәк бит. Терлекчеләр үзләре моны әллә нинди зур казанышка санамыйлар. Иң элек тәүлек буе көтү оештырылган. Башка елларда маллар көннәр-төннәр буе елга буенда гына йөрсәләр, быел җитәкчелек авыл халкының печәнгә ихтыяҗын башка юл белән хәл итәргә вәгъдә биреп пайларын хуҗалык маллары карамагына тапшырган. Ә анда үлән, кем әйтмешли, бил тиңелтен. Өстәвенә яшел азык, катнаш азык, барда да бирелә әле үзләренә.

Малларны карау режимы да төгәл үтәлә. Савучылар да тырышалар. Әгәр дә элегрәк хуҗалыкта аларга кытлык булса, хәзер терлекчеләрне сайлап алу мөмкинлеге бар. Әнә Зоя Петрованы гына карагыз. 14 еллап эшли ул фермада. Бик тырыш. Әле күптән түгел савучыларның район конкурсында катнашып та яхшы нәтиҗә күрсәтте. Шулай булмыйни: бүген һәр сыердан уртача 20 килограмм сөт савучы бит ул. Зинаида Павлова, Светлана Зиновьева, беренче кат бозаулаган сыерларны караучы Елизавета Мөхәммәтсафина группаларында да савым югары быел. Кызыксындыру булгач, алны-ялны онытып эшлиләр кызлар. Сөтнең сыйфатына да зур игътибар бирелә. Элегрәк савылган сөтне сыешлыкларга салып фермага илтәләр һәм суыткычка бушаталар, аннан соң янә сөт-май комбинатына озаталар иде. Быел исә суыткыч лагерьда ук. Шуның нәтиҗәсе буларак, хуҗалыкның быелның 5 аенда дәүләткә сатылган сөтенең шактый өлеше суытып сатылган иде. Продукциянең 89 проценты исә I сорт белән кабул ителде.

Билгеле инде, сыйфат күрсәткечләре турында сөйләгәндә, белгечләрнең дә бу эштә ролен ассызыклыйсы килә. Хуҗалыкта әле яңа гына эшли башлаган баш зоотехник Иван Пинин сөт терлекчелеген даими күзәтү астында тота. Яшь, энергияле белгеч үз дигәненә ирешә дә. Ферма мөдире Малик Сафин да терлекчелектә тәҗрибәле кеше. Эш көнен җәйләдән башлый һәм шунда ук төгәлли дә ул. Көн дәвамында кышка абзарларны реконструкцияләүче осталар янында да булырга өлгерә ул. Шулай, тулаем терлекчелектә үзгәрешләр уңайга барганда аны бер эзгә төшергәнче максат куеп, уйлап эшләсәң генә алга таба йөк җиңел булачак бит ул. Җәмгыять җитәкчелеге дә төп игътибарын шуңа юнәлтә.

Шунысы куанычлы, эшләренә күрә ашлары да күренә сөлчәлеләрнең.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## 01 хәбәр итә

### *Янгыннар саны кимеми*

Янгыннар анализыннан күренгәнчә, аларның байтак өлеше җәйге чорга туры килә. Ут белән сак эш итмәгән, тимер чыбыклар, электр җиһазлары төзек булмаган, янгын куркынычсызлыгының элементар таләпләре үтәлмәгән җирдә мондый күңелсез очраклар аеруча еш күзәтелә.

Җәйге чорда яшен дә бик куркыныч. Еш кына ул янгын чыгуга сәбәп була, халык хуҗалыгына зур зыян сала. Мисал өчен июнь башында «Заря» КХАнда яшен сугу сәбәпле такта ярдыру цехында янгын чыкты. Шул ук көнне Абрыскино авылында Л.Фролова һәм А.Федорованың йорт яны корылмалары янып китте. Анда да янгын яшен сугудан килеп чыкты.

Яшеннән саклану чарасы булса Якушкино авылында яшәүче Е.Магусеваның торак йортында да янгын чыкмас иде, мөгаен.

Елаур авылында А.Горшков йортында чыккан янгын нәтиҗәсендә аның йорт милкенең бер өлешенә зыян килде.

6 нчы июньдә Чулпан авылында К.Хәниев хуҗалыгында каралты-кура янып китте. Һәр икесендә дә күңелсез очракка китергән сәбәп электр җиһазларының төзек булмавы иде.

Бер көн соңрак Мичурин исемендәге хуҗалык фермасында һәм Ключи поселогындагы азык цехында янгын чыкты. Сәбәбе котельня җиһазларын файдалануны дөрес оештырмау.

Әмма моңа да карамастан, бүгенге көндә район хуҗалыкларының байтакларында янгын сүндерү деполары начар эшли, кайберләрендә бөтенләй дә юк. Тышта температура югары булганда хуҗалыклар җитәкчеләренә бу хезмәтнең эшен оештыруга җитдиерәк якын киләсе дә бит...

**Ә.ӘЮПОВ,**

**Октябрь янгын частеның өлкән инспекторы.**

# TV

## ПОНЕДЕЛЬНИК, 30 ИЮНЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 “Чулпан”
18.00 Мультфильм
18.15 “Бизнес - коктейль”
18.45,20.45 “Җиһан”
19.00 “Замандаш” циклыннан
19.30 “Выбор профессии”
19.45,21.45 Новости
20.00 “Арча ягына килегез”
20.30 “Әлли - бәлли - бәү”
21.00 “Золотая мина” 1-я серия
22.25 “Карт - бланш”

### ОРТ

6.00 Телеканал “Доброе утро”.
9.00 12.00 15.00 18.00 23.45 Новости.
9.15 18.20 “Девушка по имени Судьба”. Сериал.
10.00 Поле чудес.
10.55 Футбольное обозрение.
11.25 Домашняя библиотека.
11.30 19.35“Угадай мелодию”.
12.15 Пьер Ришар в комедии “Налево от лифта”.
13.45 23.55 Баскетбол. Чемпионат Европы. Мужчины.
14.30 Человек и закон.
15.20 “Сказки тихого часа”. Мультсериал.
15.45 Марафон-15.
16.05 Звездный час.
16.40 “Гарри - снежный человек”.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 “Вокруг света”.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 Программа “Мы”.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 “Полтергейст-2”.
22.35“Серебряный шар”.Вивьен Ли. Ведущий-В.Вульф.
23.15 “Когда казаки плачут”.
1.00 Пресс-экспресс.

### “РОССИЯ”

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25 “Клубничка”.
9.35 Сам себе режиссер.
10.05 “Терем-квартет”.
11.15 Парламентский вестник.
11.45 Графоман.
12.00 “Подслушанный разговор”. Х/ф.
13.20 “Путешествие к заокеанским алкоголикам”. Фильм 1-й.
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 “Магазин недвижимости”.
14.25 “Дворянское собрание”.
15.05 “Иванов, Петров, Сидоров и другие”.
15.45 Вместе.
16.10 Ваше право.
17.15 “Там-там новости”
17.25 “Лукоморье”
17.50 “Посмотри на себя”
18.05 “Россияне”
18.20 “Пульс”
18.55 Волейбол.Мировая лига.
20.35 “Добрый вечер”
21.15 “Школьный вальс”. Х/ф.
23.35 VIP.
23.50 “Дежурная часть”.
0.15 Волейбол. Мировая лига. Финальный турнир.
1.15 “На ночь глядя”

### РИО

19.00 “Шесть самарских новостей”.
19.05 “Студия ДВА”.
19.55 “Шесть новостей”.
20.05 Ток-шоу “МУЗЫКА И ПРЕССА”: “АКУЛЫ ПЕРА” - “ЭКС ББ”.
21.00 “Шесть новостей”.
21.15 “Шельменко-денщик”.
23.00 “Шоу Бенни Хилла”.
23.15 КАТАСТРОФЫ НЕДЕЛИ.
23.45 “Шесть новостей”.
00.00 Дорожный патруль.

## ВТОРНИК, 1 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 “Чулпан”.
18.10 Мультфильм
18.25 “Прямая связь”
18.45, 20.45 “Җиһан”
19.20 “Клуб Болл”
19.45,21.45 Новости
20.00 “Карт - бланш”
20.30 “Әлли - бәлли - бәү”
21.00 “Золотая мина”.
22.20 “Виртуальные впечатления”.

### ОРТ

6.00 Телеканал “Доброе утро”.
9.00 12.00 15.00 18.00 0.00 Новости.
9.15 18.20“Девушка по имени Судьба”.
10.00 Программа “Мы”.
10.50 Смехопанорама.
11.25 Домашняя библиотека.
11.30 19.35“Угадай мелодию”.
12.15 “Что? Где? Когда?”
13.35 23.15 Баскетбол.
15.20 “Сказки тихого часа”.
15.45 Кварьете “Веселая квампания”.
15.55 Мультитроллия.
16.15 Волшебный мир, или Синема.
16.40 “Гарри - снежный человек”.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 “Вокруг света”.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.05 Тема.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 “Эта женщина в окне”Х.ф
0.45 Пресс-экспресс.

### “РОССИЯ”

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25“Клубничка”.
9.35 Караоке по-русски.
10.10 19.00 “Санта-Барбара”.
11.15 Пульс.
11.40 Графоман .
13.55 “Магазин недвижимости”.
14.25 Арена для сенсаций.
14.50 Ноу хау.
15.05 “Иванов, Петров, Сидоров и другие”.
15.45 Образ жизни.
16.10 Ваше право.
17.15 “Там-там новости”
17.25 “Лукоморье”
17.50 “Посмотри на себя”
18.05 “Россияне”
18.20 Новое Пятое колесо
20.35 “Добрый вечер”
21.10 “Короткие встречи”.
23.35 VIP.
23.50 Момент истины.
0.20 Волейбол. Мировая лига. Финальный турнир.
1.20 Звуковая дорожка.
2.15 “На ночь глядя”.
2.30 “Товары - почтой”.

### РИО

19.00 “Шесть самарских новостей”.
19.05 “Студия ДВА”.
19.55 “Шесть новостей”.
20.05 Ток-шоу “ПРОФЕССИЯ”: “Мясник”.
21.00 “Шесть новостей”.
21.15 Сериал “Династия II (Семья Колби)”.
22.15 Те Кто.
22.45 Детективный сериал “Улица “Желтая нить”.
23.45 “Шесть новостей”.
00.00 Дорожный патруль.

## СРЕДА, 2 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 “Чулпан”
18.00 Мультфильм
18.45,20.45 “Җиһан”
19.00 “Авыл”
19.30 “Три бардовских аккорда...”
19.45,21.45 Новости
20.00 “Точка опоры”
20.30 “Әлли - бәлли - бәү”
21.00 “Человек с бульвара Капуцинов”

### ОРТ

6.00 Телеканал “Доброе утро”.
9.00 12.00 15.00 18.00 0.30 Новости.
9.15 18.20 “Девушка по имени Судьба”.
10.00 Тема.
10.40 “В мире животных”
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 19.35“Угадай мелодию”.
12.15 “Остров сокровищ”
13.15 Мультфильм.
13.35 Баскетбол.Чемпионат Европы.
15.20 “Сказки тихого часа”. Мультсериал.
15.45 Кактус и Ко.
15.55 До-ми-соль.
16.15 Зов джунглей.
16.40 “Гарри - снежный человек”.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 “Вокруг света”.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
20.00 “В поисках утраченного”.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40“Парень из нашего города”.
23.15 “ТЭФИ-97”.
23.50 “50 х 50”.
0.45 Пресс-экспресс.

### “РОССИЯ”

7.00 8.000 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25 “Клубничка”.
9.35 L-клуб.
10.05 Волейбол. Мировая лига.
11.15 Новое пятое колесо.
11.45 Графоман.
12.00“Молодой Пикассо”. Х/ф
13.30 “Контакт”. М/ф.
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 “Магазин недвижимости”.
14.25 Подиум Д”Арт.
15.05 “Иванов, Петров, Сидоров и другие”.
15.45 Парламентарий.
16.10 “Темная” для А.Лебедя”
17.55 Футбол. Чемпионат России. “Алания”(Владикавказ) - “Спартак”(Москва).
20.35 Добрый вечер.
21.10 “Иванов катер”. Х/ф.
23.35 VIP.
23.50 Волейбол. Мировая лига.
0.50 Кафе Обломов.
1.30 “На ночь глядя”.
1.45 “Товары - почтой”.

### РИО

19.00 19.55 21.05 23.45 “Шесть самарских новостей”.
19.05 “Студия ДВА”.
20.05 Ток-шоу “Я САМА”
21.20 Сериал “Династия II (Семья Колби).
22.15 Те Кто.
22.45 Детективный сериал
00.00 Дорожный патруль.

## ЧЕТВЕРГ, 3 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 “Чулпан”
18.25 Мультфильм
18.45,20.45 “Җиһан”
19.00 “Вопросы из записной книжки”
19.25 “Эхо голоса твоего”.
19.45,21.45 Новости
20.00 “ГАИ - информ”
20.10 Хәснул Вәлиуллин җырлары
20.30 “Әлли - бәлли - бәү”
21.00 “Курьер”

### ОРТ

6.00 Телеканал “Доброе утро”.
9.00 12.00 15.00 18.00 0.25 Новости.
9.15 18.20 “Девушка по имени Судьба”.
10.00 “В поисках утраченного”.
10.40 “Клуб путешественников”
11.35 Домашняя библиотека.
11.40 Смак.
12.15 "Остров сокровищ"
13.25 "Очевидное - невероятное"
13.55 Мультфильм.
14.10 "Театр плюс TV"
15.20 “Сказки тихого часа”. Мультсериал.
15.45 Остров Чунга-Чанга.
16.15 Лего-го!
16.40 “Гарри - снежный человек”.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 “Вокруг света”.
19.05 Погода.
19.10 Час пик.
19.35 Джентльмен-шоу.
20.05 Моя семья: неравный брак.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 А.Пачино и Н.Кински в фильме “Революция”.
23.50 Магия: мир сверхъестественного.
0.30 Пресс-экспресс.

### “РОССИЯ”

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25 “Клубничка”.
9.35 Бесконечное путешествие.
10.10 19.00 “Санта-Барбара”.
11.15 Избранные.
11.45 Графоман.
11.55 “Молодой Пикассо”.Х/ф.
13.40 Ретро-шлягер.
13.55 “Магазин недвижимости”.
14.25 “Встреча в ЦДРИ”. Г.Матвеев.
14.50 “На дорогах России”.
15.05 “Иванов, Петров, Сидоров и другие”.
15.45 На пороге века.
16.10 “Темная” для А.Коха.”.
17.15 Там-там новости.
17.25 Лукоморье.
17.50 Посмотри на себя.
18.05 Россияне.
18.20 Люди,деньги, жизнь...
20.35 Добрый вечер.
21.15 Мастера искусств - пограничникам. Концерт.
23.35 VIP.
23.50 Хамелеон.
0.30 По вашим письмам.
1.10 “На ночь глядя”.
1.25 “Товары - почтой”.

### РИО

19.00 “Шесть самарских новостей”.
19.05 “Студия ДВА”.
19.55 “Шесть новостей”.
20.05 Ток-шоу“СДЕЛАЙ ШАГ”.
21.00 “Шесть новостей”.
21.15 Сериал “Династия II (Семья Колби).
22.15 Те Кто.
22.45 Детективный сериал “Улица “Желтая нить”, 4 серия.
23.45 “Шесть новостей”.
00.00 Дорожный патруль.

## ПЯТНИЦА, 4 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 “Чулпан”
17.55 “Отцы”.
18.45.20.45 “Җиһан”
19.25 “Дин һәм тормыш”
19.45,21.45 Новости
20.00 “В Госсовете Татарстана”
20.30 “Әлли - бәлли - бәү”
21.00 “Җомга көн кич белән”
22.00 “Видеоспорт”.
22.20 “Замандаш” циклыннан

### ОРТ

6.00 Телеканал “Доброе утро”.
9.00 12.00 15.00 18.00 23.35 Новости.
9.15 18.20 “Девушка по имени Судьба”.
10.00 Моя семья: неравный брак.
10.40 Пока все дома.
11.20 Домашняя библиотека.
11.30 Играй, гармонь любимая!
12.15 "Остров сокровищ"
13.20 "Джентльмен - шоу"
13.50 Мультфильм.
14.10 "Театр плюс TV"
15.20 “Сказки тихого часа”. Мультсериал.
15.45 Фильм-сказка. “Степанова памятка”.
17.05 ...До 16 и старше.
17.30 Вокруг света.
19.10 Погода.
19.15 Человек и закон.
19.45 Поле чудес.
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.40 “Большая перемена”Х.ф
22.50 Взгляд.
23.45 Баскетбол. Чемпионат Европы. Мужчины.
1.05 Пресс-экспресс.

### “РОССИЯ”

7.00 8.00 11.00 14.00 17.00 20.00 23.00 Вести.
7.15 8.15 С добрым утром!
9.00 Православный календарь.
9.05 16.25 “Клубничка”.
9.35 “Аншлаг” представляет.
10.10 19.00 “Санта-Барбара”.
11.15 “Люди, деньги, жизнь...”.
11.45 Графоман.
12.00 “Молодой Пикассо”. Х/ф
13.00 “Путешествие к заокеанским алкоголикам”. Фильм 2-й.
13.20 “Маленькие приключения”. М/ф.
13.35 Ретро-шлягер.
13.55 “Магазин недвижимости”.
14.25 Момент истины.
14.50 “Красная книга”.
15.05 “Иванов, Петров, Сидоров и другие”.
15.45 Золотая карта России.
16.10 “Ничего, кроме...”.
17.15 “Там-там новости”
17.25 “Лукоморье”
17.45 “Посмотри на себя”
18.05 “Россияне”
18.20 “Парламентский вестник”
20.35 “Добрый вечер”
21.10 “Живет такой парень”. Х/ф.
23.35 VIP.
23.50 Волейбол. Мировая лига. Финальный турнир.
0.50 Тихий дом.
1.45 Ночной экспресс.
2.25 “На ночь глядя”.
2.35 “Товары - почтой”.

### РИО

19.00 “Шесть самарских новостей”.
19.05 “Студия ДВА”.
19.55 КИНОТЕАТР ТВ-6. “Пожиратель змей”.
21.40 “Шесть новостей”.
21.55 Клуб “12 КОПЕЕК”.
22.25 КИНОТЕАТР ТВ-6. “Пожиратель змей-2”.
00.15 “Шесть новостей”.
00.30 Дорожный патруль.

## СУББОТА, 5 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 “Чулпан”
17.15 “Автомобиль, скрипка и собака Клякса”
18.45 “Җиһан”
19.00 “Бизнес - коктейль”
19.35 Из “личной жизни... “дома
19.45 Новости
20.00 “Әлли - бәлли - бәү”
20.15 “Габбас хәзрәт”.
21.25 Мирсәет Сөнгатуллин җырлый
21.45 “Досье - 02”
22.00 “Шаян - шоу”

### ОРТ

8.00 Тарапунька и Штепсель в комедии “От и до”.
9.05 М/ф “Лесные путешественники”, “Комаров”.
9.40 Лотто-Миллион.
9.45 Домашняя библиотека.
10.00 15.00 18.00 Новости.
10.10 Слово пастыря. Митрополит Кирилл.
10.30 Утренняя почта.
11.05 “Каламбур”.
11.35 Смак.
11.55 Возвращение Третьяковки. История одного шедевра.
12.20 “Однажды двадцать лет спустя”.
13.40 А.Филиппенко в программе “Если...”.
14.25 Очевидное - невероятное.
15.20 “Союзмультфильм” представляет.
16.10 Московский “Триумф” Е.Кисина.
16.40 В мире животных.
17.15 “Колесо истории”.
18.20 КВН-ассорти.
18.50 Погода.
18.55 “Мужики!”Х.ф
20.45 Спокойной ночи, малыши!
21.00 Время.
21.55 “Большая перемена”. 2-я серия.
23.10 Баскетбол. Чемпионат Европы. Мужчины.
0.45 Рождение “Битлз” в фильме “Пятый в квартете”.

### “РОССИЯ”

8.00 Утренний экспресс.
8.55 “Товары - почтой”.
9.05 “Меморина”. Телеигра.
9.30 Клуб “Адреналин”.
9.45 Доброе утро, страна!
10.30 В мире животных.
11.00 14.00 20.00 Вести .
11.15 “Хочу в артисты!”.
11.55 Наш сад.
12.20 “Русский хоровод”.
13.00 “Анонимные собеседники”.
13.25 Караоке по-русски.
14.20 “ОП-центр”. Х/ф (США).
15.10 Бесконечное путешествие.
15.35 Двойной портрет.
16.05 “Галерея РТР”.
16.30 Телескоп.
17.10 Мужчина и женщина.
17.55 Субботний вечер с Ю.Башметом.
18.55 Волейбол. Мировая лига.
20.35 Сам себе режиссер.
21.10 “Любовь и пули”. Х/ф
23.00 Момент истины.
23.55 Волейбол. Мировая лига.
1.10 Репортер.
1.30 Программа “А”.

### РИО

8.35 М/ф “Башмачки”, “Мышонок-недотепа”.
9.00 “Цептер-Приз”.
9.10 Детский сеанс. “Веселые истории”.
10.45 “ЕРАЛАШ”.
11.20 Сериал о природе “Дикая природа Австралии”.
12.25 ТЕЛЕМАГАЗИН “Спасибо за покупку!”
13.00 Доксериал “Теория заговоров”: “Заговор с целью убийства Папы Римского”.
14.00 ДИСК-канал для детей.
14.55 Ток-шоу “Я САМА”:"История любви с предубеждением”.
15.55 Ток-шоу “ПРОФЕССИЯ”: “Мясник”.
16.50 “Клуб одиноких сердец”.
17.20 “Семья Робинзонов” (Канада-Австралия).
18.15 “Ералаш”.
18.25 “Хроника недели”.КТВ “ЛУЧ”(г.Сызрань).
18.45 “Домовой”.Тележурнал.
19.00 Документальный сериал “Великие ценности мира”.”Греция”.
19.55 СКАНДАЛЫ НЕДЕЛИ.
20.30 Юмористическая программа “ОСП-студия”.
21.20 “Фитиль”.
21.35 КИНОТЕАТР ТВ-6.
23.25 “Шесть новостей”.
23.35 “ОБОЗ”.
00.30 Дорожный патруль.

## ВОСКРЕСЕНЬЕ, 6 ИЮЛЯ

### «ТАТАРСТАН»

7.00 - 8.00 “Чулпан”
18.00 “Сандугач керде күңелгә”
19.00 “Под созвездием Лиры”
19.30 “ТОН”
20.15 “Автокалейдоскоп”
20.30 “Телебуклет”
20.40 “Әлли - бәлли - бәү”
20.50 “Музыкаль сәхифә”
21.15 “Тормыш асылы”
22.10 “Сирены”

### ОРТ

8.00 Н.Еременко в приключенческом фильме “Я объявляю вам войну”.
9.25 “Дюймовочка” М.ф
9.55 Спортлото.
10.00 15.00 23.30 Новости.
10.15 “Непутевые заметки” Дм.Крылова.
10.30 Пока все дома.
11.05 Утренняя звезда.
11.55 Служу России!
12.25 Играй, гармонь любимая!
12.55 Сельский час.
13.20 “Подводная одиссея команды Кусто”. “Сумерки над Амазонией”.
14.10 Айболит и Бармалей”. М/ф.
14.25 Смехопанорама.
15.15 “Приглашение к музыке”.
15.45 Баскетбол. Чемпионат Европы.
16.45 Мультфейерверк.
17.30 “Один на один”.
18.00 Футбольное обозрение.
18.30 Клуб путешественников.
19.15 Погода.
19.20 “Строго на юг”Х.ф
20.50 Киноафиша.
21.00 Время.
21.40 “Большая перемена”. 3-я серия.
22.50 Баскетбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Финал.

### “РОССИЯ”

8.00 Утренний экспресс.
8.55 “Торговый дом “Ле Монти”.
9.10 “Солти”. Телесериал (США).
9.35 “У всех на устах”.
9.50 Доброе утро, страна!
10.30 Присяга.
11.00 Вести в одиннадцать.
11.15 Русское лото.
11.55 “Без пяти двенадцать”.
12.00 Книжная лавка.
12.25 Человек на земле.
12.50 “Трое на острове”. М/ф.
13.10 Новая Россия.
13.30 “Сад культуры”.
14.00 20.00 Вести.
14.20 “ОП-центр”. Х/ф 2-я серия.
15.15 Волшебный мир Диснея.
16.10 “Когда Витебск был Парижем”.
16.35 “Довгань-шоу”.
17.05 “Репортаж ни о чем”.
17.20 Футбол без границ.
17.50 “Праздник терпсихоры”.
18.40 L-клуб.
19.20 “Аншлаг” представляет.
20.35 “Четвертая власть”.
21.00 Старая квартира. 1947 год.
22.05 У Ксюши.
22.35 “К-2” представляет.
23.30 Площадь звезд. И.Понаровская.
0.20 Ночная жизнь городов мира. Лас-Вегас.

### РИО

8.45 М/ф “Дерево и кошка”, “Играй, моя дудочка”.
9.10 Детский сеанс. “На графских развалинах”.
10.25 “Спасибо за покупку!”
10.50 “ПАЛЬЧИКИ ОБЛИЖЕШЬ”.
11.30 “НАЗЛО РЕКОРДАМ!”
11.55 “Дикая природа Австралии”.
13.05 “КАНОН”.
13.40 Ток-шоу
14.35 Конкурс красоты “МИСС МОСКВА - 97”.
15.45 СПОРТ НЕДЕЛИ.
16.15 “ЕРАЛАШ”.
16.40 “МОСКВА Ивана УСАЧЕВА”.
16.55 Сериал по выходным “Семья Робинзонов”.
17.50 “Шесть новостей”.
18.00 “Ералаш”.
19.35 “Европа плюс” представляет.
20.10 “Фитиль”.
20.30 “Сокровище моей семьи” (Россия-США).
22.20 “Шоу Бенни Хилла”.
22.40 КИНОТЕАТР ТВ-6.
00.25 “ПАРТИЙНАЯ ЗОНА”.

## *Бездә кунакта-*

# Айдар Фәйзрахманов :
# «САБАНТУЙЛАРГА БЕЗНЕ КӨТСЕННӘР»

-Беләсезме, мин бит беркайчан да Норлатта булганым юк. Караңгы,бигрәк тә культура ягыннан артта калган кешеләр яшидер монда, болар минем җырларымны ишеткәннәре бармы икән,ничек каршы алырлар, дип килгән идем. Безнең өчен бит халыкка мәгълүм булуың бик мөһим, чөнки иҗатыбыз алар өчен, халык тормышы белән үрелеп бара. Һәм менә гаҗәпләнүемнең чиге юк. Норлат шәһәр икән ләбаса, халык мине белә,җырларыма кушылып җырлый, көйләремә кушылып бии.

**-Норлатлылар һич тә караңгы түгел. Шәһәрдә күбесе телевидениедән 5-6 канал карый.Сез бик күптән сәхнәдә бит, гастрольләрдә дә күп йөрергә туры килгәндер, берегә бер дә килеп чыга алмагансыз.**

-Әйе, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында эшли башлавыма 16 ел булды.Бу чорда кайларда гына булырга туры килмәде. «Алтынчәч», «Башмагым» нар белән Австрия, Франциядә дә булып кайттым. Мин опера арияләрен башкарам. Безнең татар халкы нигәдер операны аңлап бетерми, аның сүзеннән үк йөзләре чытыла. Ә менә шул кешеләр безнең театрда булып киткәннән соң карашлары бөтенләй кире якка үзгәрә, хәйран калып, йотлыгып тыңлыйлар. Минем өчен опера арияләре җыр сәнгатенең иң югары, иң нечкә баскычы, шуңа да үземне зур горурлык белән опера җырчысы дип саныйм.



*Быелгы сабан туенда Татарстанның атказанган җырчысы Айдар Фәйзерахманов мәйданның иң якты йолдызы булды дисәк, һич ялгышмабыздыр, мөгаен.Ул киң күңелле, иң дәртле җырлары белән бөтен мәйданны җанландырып, халык күңелен күрә алды,күпләр урыннарында тыныч кына тора алмыйча, уртага тартылдылар.*

*«Рәхәтләндердең» дибез аны чираттагы бер чыгышыннан каршы алып.«Юк, үзем рәхәтләндем,-дип җавап бирде ул.-Халыкның мине шулай җылы каршылавына хәйран калып та рәхәтләндем...»Хәер, Айдарның тәмле телле,ягымлы, ачык йөзлелеген, Норлат халкына карата теләктәшлеген тоеп безгә дә хәйран калырга туры килде.Аның белән әңгәмәбезне укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәргә булдык.*

Ә сездә булмауның сәбәпләре булгандыр инде.Халыкны сәнгатькә тарту, культурага карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү ул бит иң әлек район җитәкчелегенең бу юнәлештә эшчәнлегенә бәйләнгән.Сүз уңаенда шуны да әйтәсе килә,без Фатыйх Сәүбәнович белән авылдашлар, аның сабан туена чакыруын куанып кабул иттем һәм килүемә дә үкенмим.

**-Айдар, сез сабан туе өчен программагызны махсус төзегәнсездер, шулай бит. Сезнең телевидение тапшыруларында моңлы татар халык җырларын сузуыгызны күбрәк ишетергә туры килә, ә монда һәркайсы биергә чакыра сыман.**

-Шулай булмый мөмкин түгел, һәр көйнең үз урыны буладыр, минемчә.Сабан туенда бит моңнан тәм табып булмый, монда күңел күтәрергә, биергә, куанырга кирәк. Халык җыеннарында нәкъ шундый җырлар җиңел кабул ителә.

**-Айдар, кайчан җырлый башладыгыз?**

-Үземне белгәннән бирле.Гармунда уйнарга өйрәндем, үзем уйнап Илһам абый Шакировның җырларын суза идем.Бөтен тормышым җырга бәйләнгән минем.

**-Гаиләгез бармы?**

-Әйе, ике кызым- Чулпан белән Айгөл бар.

**-Тагын сезнең чират җиткән, бугай...**

-Җырлыйбыз әле без... Халык белән турыдан-туры аралашу минем өчен зур бәхет,чөнки алар иң рәхмәтлеләр дә.Сезнең аша норлатлыларга теләкләремне җиткерәсем килә.Заманалар аңлаешсыз, авыр хәзер,күпчелек һәммә нәрсәгә дә битараф карый башлады. Шуңа карамастан, халык элеккедән күпкә әйбәтрәк яши, дип уйлыйм мин.Булганның кадерен белеп,өмет белән, ачык күңел белән яшәсеннәр иде. Һәм, әлбәттә,сабантуйларга безне көтсеннәр.

Әңгәмәдәш
**Ф. ЗЫЯТДИНОВА.**

## әниебез

Әни. Аңардан да якын кеше бармы икән бу дөньяда?! Юктыр, мөгаен. Күкрәк сөтен имезеп үстергән, елаганда юаткан, иркәләгән, кайгыңны уртаклашкан, шатлыгыңа сөенгән, гомумән, бар булганын баласына биргән кеше бит ул ана.

Без дә үз әниебезне - Асия Таһир кызы Сабитованы өзелеп яратабыз, аның һәрчак сау - сәламәт, көр кәефле булуын, тигез канатлы гомер итүен телибез Юкса, аның тормышында кайгы - хәсрәтләр, борчу-мәшәкатьләр дә аз булмаган. Тормыш юлы да катлаулылыгы белән аерылып торды. Әмма шуңа сөенәбез, ул авырлыкларга һичкайчан бирешмәде, һәрвакыт ачык йөзле, киң күңелле булып кала алды. Эшендә дә гел хөрмәтле булды: нинди вазифаларны да күңел биреп, җиренә җиткереп башкаруы сәбәпче булгандыр моңа. Баштарак елларда ун еллап «Дуслык» район газетасы редакциясендә корректор иде, аннан озак еллар тимер юл станциясендә оператор булып эшләде.

Кеше буларак та киң холыклы әниебез. Ярдәмчесез,ялгыз карчыкларга карата аеруча мәрхәмәтле ул. Шулай бер вакыт картлык көнендә берүзе генә калган карчыкны карады ул. Әби-карчыкны җирләүдә дә булышты.

Гомумән, әниебез һәр яктан килгән, уңган, булган кеше. Шуңа да без аны юбилее - 55 яшь тулуы белән кайнар котлап, аңа балалары исеменнән саулык - сәламәтлек, иминлек, озын гомер телибез.

**Балалары.**

## *Шифаханә*

## БОРЧЫЛУ ХАЛӘТЕ




Гадәттә, кешеләр үзләренең борчулы халәттә булуын аңлап җиткермиләр, табибка мөрәҗәгать итмиләр. Борчылу халәте (стресс) - авыруның бер төре.

Менә аның билгеләре:

* туктаусыз ярсу.

* еш кына баш авырту.

* фикер таркаулыгы, хәтер начараю.

* көтмәгәндә йөрәк тибеше көчәю яки аның ритмы бозылу.

* сәбәпсез борчылу.

* умырткада авырту тою.

* үзен гаиләдә яки эштә хөрмәт итмиләр дигән фикер тою.

* йә бик нык ачыгу, йә аппетит югалу.

* көн азагында гына яхшы һәм сыйфатлы итеп эшли алу.

* җенси якынлыкка омтылуның йә көчәюе, яки бөтенләй сүнүе.

* ашказанында азык эшкәртүдә кыенлыклар туу.

* вакыт - вакыт тын җитмәү.

* сезгә кешеләр артык зур таләпләр куя кебек тоелу.

**Е.ТАРАСОВА,**
**табиб - психотерапевт.**

## Белдерүләр

### Сатабыз

**1996 елгы ВАЗ-2106.**
Адрес: Красноармейская ур., 71-1

***

**УАЗ-469**. Тел: 5-20-71,16.00 сәг. соң.

***

**Төньяк микрорайонында төзелеп бетмәгән йорт**. Тел: 5-21-94.

***

**1-2 көн эчендә язып мәрмәр плитәләр, өйгә үк китерәм. Бәясе - килешү буенча**.Адрес: Ленинградская ур., 14. 324-Б номерлы таныклык.

***

**18 кв. метрлы 1 бүлмәле фатир.** Арадашчы телефоны-5-12-14, (7 дән-16.00 кадәр).

***

**Ашыгыч төстә 20 куб.метрлы газобетон,кыйммәт түгел.** Советская ур.,34.

***

**1995 елгы ВАЗ-21061.** Тел: 2-18-83.

***

**Өч бүлмәле хосусыйлаштырылган фатир,кыйммәт түгел.** Адрес: Московская, 5-45, 17 сәг. соң.

***

**Ашыгыч төстә. «Нива» машинасы, кыйммәт түгел.** Заречный авылында Семеновларга мөрәҗәгать итергә.

***

### Алмаштырабыз

**Кормыш микрорайонында барлык уңайлыклары булган 2 бүлмәле фатирны - өстәмә түләп 1 бүлмәлегә.** Тел: 5-11-30.

***

### Төрлесеннән

**Булатов Эдуард Витальевич исеменә 1992 елның 20 июнендә бирелгән АВ категорияле АБ 382862 номерлы тракторчы таныклыкны югалу сәбәпле,гамәлдән чыккан дип исәпләргә**

***

## Эшкә чакырабыз

***Ачык типтагы «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыяте яңа ЛТЗ - 50 тракторларына ( француз бөркегечләре) тәҗрибәле механизаторларны гына эшкә ала. Эш - йөреп эшли торган, хезмәт хакы һәр айның 10 нчы числосында даими түләнә,ул 5 миллионга кадәр. Өч көн эчендә 10 механизатор кирәк, характеритстика яки рекомендация булуы шарт.***

## *Рәхмәт белдерәбез*

**Кадерлебез Әлфис Әмир улы Гыйләҗевны соңгы юлга озатуда зур матди һәм мораль ярдәм күрсәткән, тирән югалту кайгыбызны уртаклашкан район хакимиятенә, район финанс бүлеге, Норлат шәһәр Советы, сәүдә базасы, салым испекциясе, куптармаклы производство предприятиясе, 1 нче мәктәп, җәмәгать туклануы коллективларына, туганнарыбызга, якыннарыбызга, авылдашларыбызга, күршеләребезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез.**

*Әнисе, хатыны, кызы, туганнары.*

## Н.Октябрь янгынга каршы эшләр РСУ сы түбәндәге эшләргә килешүләр төзи:

**1. Газ приборлары өчен акт биреп төтен үткәргечләр төзү;**

**2.Төрле типтагы казаннарны кирпеч белән әйләндереп алу.**

**3.ОХП-10 янгын сүндергечләрен кору.**

**4.Агач конструкцияләрне янгынга каршы эшкәртү.**

**5.Электр үткәргечләр һәм контур җир белән тоташтыру чыбыгының изоляциясе каршы торучанлыкны тикшерү, электр үткәргечләр ялгавын ябыштыру.**

**6.Янгын сигнализациясен монтажлау.**

**Моннан тыш сату-ОХП-10;ОП-2;ОП-5;ОУ-2; ОУ - 3; ОУ-5;ОУ-8 янгын сүндергечләре.**

**Янгын җиңсә:**

**-Д-51 мм,66 мм.**

**-баганалар, төрле гайкалар, 50 х 70 күчкечләр.**

**Барлык эш төрләренә лицензия бар.**

**Газ ягулыгына төтен үткәргечләр төзү, казаннарны кирпеч белән әйләндереп алуны лицензиясе булмаган кешегә башкару тыела.**

Адрес: Норлат шәһәре, Лихачев ур.,4. тел: 2-18-85.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс. урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7204